КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 апрель г.Казань № 334

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1258 нче карары белән расланган 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы терри-ториясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2019 ел, 30 декабрь, 1258 нче карары белән расланган 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы терри-ториясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның VI бүлегендә:

14.8 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Көндезге стационарлар шартларында беренчел медик-санитар һәм махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәткәндә пациентларны дәвалау белән тәэмин итү, психиатрия, наркология, фтизиатрия профилендәге көндезге стационарлардан тыш, күздә тотылмый, шул ук вакытта көндезге стационарларда пациентларны ашату өчен урын каралырга тиеш.»;

программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин